ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАРЫ

№7 11 ноябрь 2022 ел

" Аксубай муниципаль районының
Иске Үзи авыл җирлеге
Яңа Мокшино авылында халык җыенын билгеләү
һәм гражданнарның үзара салым чараларын
кертү һәм файдалану турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча Яңа Мокшино авылы, Ленин ур., 20 йорт;Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Мокшино авылында үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә: 1 группа инвалидлардан, БВС ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Украинада катнашучы гражданнарның гаиләләреннән тыш; җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан түбәндәге эшләрне башкаруга ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юл полотносын урнаштыру (грунт күтәрү, урамнарны вак таш белән яңарту)
- щебень сатып алу;

2. ТКО туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм ТКО транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- ТКО контейнерларын сатып алу;

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегенең информацион стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 10 көн эчендә игълан итәргә http://aksubaevo.tatar.ru.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова